ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

11.08.2015 г. Казань № 80

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында

2014 елның 24 декабрендәге “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы “Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе мәсьәләләре” карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе структурасына үзгәрешләр кертү турында” 1018 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә һәм 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 30 сентябрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында” ПУ-636 номерлы Указы, 2009 елның 30 декабрендәге “Аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында” ПУ-701 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, 2009 елның 30 декабрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре,

чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында” ПУ-702 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә **боерык бирәм:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә (алга таба – Инспекция) аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген расларга.

2. Исемлеккә кертелгән вазифаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә эштән куылганда 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясында каралган чикләмәләр, бурычлар һәм җаваплылык хакында аңлатырга.

3. Инспекциянең түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

2014 елның 11 декабрендәге 116 номерлы “Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында”;

2013 елның 25 июнендәге 59 номерлы “Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә аларга билгеләнгәндә һәм аларны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында”.

4. Хокукый идарәнең юридик бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык В.А.Кудряшов

ТР ДТК инспекциясенең
2015 елның “11” 08
80 номерлы боерыгына карата
№1к кушымта

**Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең иң югары вазифалар төркемендә “җитәкчеләр” категориясе вазифасы:
Инспекция башлыгы.
2. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең төп вазифалар төркемендә “җитәкчеләр” категориясе вазифалары:
Инспекция башлыгының беренче урынбасары;
Инспекция башлыгы урынбасары;
Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе.
3. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифалар төркемендә “җитәкчеләр” категориясе вазифалары:
Инспекция аппараты идарәсе башлыгы;
Инспекция аппараты бүлеге башлыгы;
Инспекция аппараты бүлеге башлыгы урынбасары;
Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе урынбасары;
Инспекциянең территориаль органы бүлеге башлыгы.
4. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифалар төркемендә “белгечләр” категориясе вазифалары:
әйдәп баручы киңәшче;
әйдәп баручы консультант;
консультант.
5. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең өлкән вазифалар төркемендә “белгечләр” категориясе вазифасы:
әйдәп баручы белгеч-эксперт.
6. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифалар төркемендә “тәэмин итүче белгечләр” категориясе вазифасы:
әйдәп баручы белгеч.
7. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең өлкән вазифалар төркемендә “тәэмин итүче белгечләр” категориясе вазифалары:
1 разрядлы өлкән белгеч;
2 разрядлы өлкән белгеч;
3 разрядлы өлкән белгеч.